КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 август г.Казань № 749

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1041 нче карары белән расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1041 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 декабрь, 1246 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктның егерме бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучының Министрлык тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә (шул исәптән Субсидия бирү

нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Субсидия бирелү шарты булып Министрлык тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүгә карата Субсидия алучының ризалыгы тора.»;

V бүлекнең исемендә:

«контроль» сүзен «контроль (мониторинг)» сүзләренә алмаштырырга;

«, максатларын» сүзен төшереп калдырырга;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Министрлык Субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, ә дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

Тәртипкә кушымтаның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы Министрлык тарафыннан Субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә (шул исәптән Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалык бирә;»;

2. Тәртипнең 2.3 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин